РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноября 2018 г. г. Альметьевск № 951

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану хокукын гамәлгә ашыру турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 маддәсе 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 19 маддәсе 3 пункты, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының 6 маддәсе 3 пункты нигезендә

Әлмәт муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану хокукын гамәлгә ашырырга.

2. 1 нче кушымта нигезендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең үз матди ресурсларын һәм финанс чараларын куллану тәртибен расларга.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Әлмәт хәбәрләре» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә (Мусин Р.Ф.) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Зак. № 2652-100

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль
районы Советының
2018 елның 15 ноябрендәге №251
карарына 1 нче кушымта

Аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдалану
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдалануның (алга таба текст буенча - Тәртип) аерым тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен оештыру нигезләрен, үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдалану тәртибен һәм очракларын билгели.

2. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз акчаларын куллану очраклары

2.1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегеннән бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз акчаларын файдалану түбәндәге очракларда гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- бирелгән вәкаләтләрне тулысынча һәм вакытында үтәүне тәэмин итү максатларында Әлмәт муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертларны үз вакытында күчермәү;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган акчаларның күләмен арттыру турында карар кабул итү, бирелгән вәкаләтләрне үтәү сыйфатын күтәрү максатларында, чираттагы финанс елына һәм план чорына Әлмәт муниципаль районы бюджеты турындагы карар белән чагыштырганда, бирелә торган акчалар күләмен арттыру турында карар кабул итү;

- әгәр районда тиешле субвенцияләрне исәпләү методикаларында кулланыла торган нормативлар артса һәм тапшырылган вәкаләтләрне тулысынча үтәү өчен өстәмә чыгымнарны гамәлгә ашыру зарур булса;

- матди ресурслар булмаса яисә җитәрлек булмаса.

2.2. Бюджет дефициты булганда тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, район тарафыннан, кире кайтарылмый торган керемнәрнең һәм (яки) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең расланган күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәренең расланган гомуми еллык күләменең 10 проценттан артыграгын үз чараларына куллану рөхсәт ителми.

## 3. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз чараларын куллану формалары

3.1. Әлеге Нигезләмәнең 2 маддәсе 1 пункты 2-4 абзацларында санап үтелгән очракларда барлыкка килә торган өстәмә чыгымнарны финанс белән тәэмин итү үз керемнәре һәм җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары хисабына гамәлгә ашырыла.

3.2. Матди тәэмин ителеш тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыручы район җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләренә җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары, биналар (урыннар), транспорт һәм башка чаралар түләүсез файдалануга бирелә.

## 4. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз акчаларын куллану тәртибе

4.1. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның үз акчаларыннан өстәмә файдалану турындагы тәкъдимнәр район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проекты белән бер үк вакытта бирелә торган документлар һәм материаллар составында яисә агымдагы финанс елы дәвамында кертелә. Кертелә торган тәкъдимдә финанс чаралары күләмнәрен исәпләү, матди ресурслар исемлеге, шулай ук, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен аларны куллануның нигезе булырга тиеш.

4.2. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның үз акчаларыннан өстәмә файдалану турында тәкъдимнәр керткәндә, чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проекты белән бер үк вакытта бирелә торган документлар һәм материаллар составында район бюджеты проектын карап тикшерүгә кертү белән бергә, район Советы чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджетын кабул итү процедурасы кысаларында әлеге мәсьәлә буенча уңай яки тискәре карар кабул итә.

4.3. Агымдагы финанс елы дәвамында тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның үз акчаларыннан өстәмә файдалану турындагы тәкъдимнәр керткәндә, район Советы әлеге мәсьәлә буенча уңай яки тискәре карар кабул итә. Агымдагы финанс елы дәвамында тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның үз акчаларыннан өстәмә файдалану турында карар кабул ителгән очракта, җирле бюджет турындагы карарга тиешле үзгәрешләр кертелергә тиеш.

4.4. Районның тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары районның үз акчаларын хезмәт өчен түләүгә һәм районның тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле башка төр чыгымнарга тотарга хокуклы.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин